## Табигый байлыклардан файдалану һәм геоэкология

838. Воронеж өлкәсендә бакыр - никель рудалары чыгара башларга планлаштыралар. Руданы чыгару җир асты ысулы белән алып барылачак. Шахталар төзегәндә, җирнең уңдырышлы катламы алынып, соңыннан булачак **<u>хвостохранилища</u>**ны кабат культивациияләүдә (рекультивациядә) файдаланылачак. Баета торган фабриканы заманча технологияләр буенча төзиячәкләр. Беренчел баету технологиясе өчен бик күп су кирәк булачак. Экологлар баету производствосы аркасында тирә-яктагы территорияләрне су белән тәэмин итеп тора торган Хопёр, Дон, Ворона елгаларына куркыныч янау ихтималы булыр дип борчылалар.

Баету фабрикасы төзү елгалар өчен нинди куркыныч тудырырга мөмкин? Шуларның икесен күрсәтегез.

Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремнең номерын языгыз.

839. 2008 нче елның 17 нче январендә Җирнең ясалма спутниклары координаталары 57° төньяк киңлек, 161° көнчыгыш озынлык булган ноктада көлне 4,5 км биклеккә ыргыту күренешен тотып алганнар. Геофизик хезмәт вәкиле

әйтүенчә, йөзләрчә километрларга сузылган көл болытлары һәм шлейфлар авиациягә куркыныч тудыралар, шуңа күрә әлеге район очышлар өчен ябык һәм якын-тирәдәге барлык аэропортлар да ябык.

Хәрәкәттәге вулканнар Россиядә кайларда бар?

1) Урал тауларында
2) Сахалин утравында
3) Алтай тауларында
4) Куриль утраулары

840. Өскә агып чыккан лавадан торган таулар ничек атала?

841. Көл болыты ясалган районны җентеклерәк өйрәнү өчен кайсы картаны сайлап алырга кирәк?

1) Африка картасын
2) Азия картасын
3) Европа картасын
4) Төньяк Америка картасын

842. Алда бирелгән текстта сүз барган  Камчатка ярымутравы территориясендә  вулканнар ясалуның нәрсәгә бәйләнгән булуын аңлатыгыз.

Җавабыгызны аерым биткә языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

---

843.  2004 нче елның июлендә Индонезиядә көчле яңгырлар була. Утрауларның берсендә биек булмаган тау башыннан шуышма (оползень) төшә. Ул тау итәгендә утырган зур булмаган  авылны каплап китә. Авыл халкы качып котылырга өлгерә.

Текстта телгә алынган авыл кайсы утрауда?

844. Ни өчен көчле яңгырлар шуышмага  (оползень) сәбәпче булган?

Җавабыгызны аерым биткә языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

845. 2008 нче елның 13 нче мартында иртән Приморьега Амур өлкәсеннән киң колачлы циклон якынлашу сәбәпле һава торышы бозыла башлый. Синоптиклар һава торышының алга таба да бозылуына прогноз бирәләр, бу исә үз чиратында Приморьега суднолар йөрешен туктатуга китерә ала.

Үзәгендә түбән атмосфера басымлы атмосфера өермәсе килүгә бәйле килеп туган нинди һава шартлары диңгез транспорты хәрәкәтенә куркыныч тудыра? Җавабыгызны аерым биткә языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

846. Текстта сүз барган РФ субъекты булган административ үзәк - шәһәр, диңгез порты ничек атала?

847. Приморье краена килгән үзәгендә түбән атмосфера басымы күзәтелгән көчле атмосфера өермәсе ничек атала?

848. Текстта телгә алынган территорияләрне җентеклерәк өйрәнү өчен Россиянең кайсы географик районы картасын сайларга кирәк?

1) Урал картасын
2) Ерак Көнчыгыш картасын
3) Себер картасын

**4)** Россиянең Европа Төньягы картасын

849. 2008 нче елның 6 нчы январендә җирле вакыт белән 7 сәг. 14 мин. Грециянең көньягында көчле җир тетрәү була. Греция даими рәвештә җир асты селкенүләре булу куркынычы астында яши.

Ни өчен Грециядә җир тетрәүләр еш була? Җавабыгызны аерым биткә языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

850. Җир тетрәүләр халыкны бәла-казага дучар итә. Халыкны махсус хезмәт күрсәтү оешмалары аша бу турыда кисәтү җир тетрәү китерергә мөмкин һәлакәтләрдән коткарып кала ала. Түбәндәге исемлектә китерелгән илләрнең кайсысына шундый махсус хезмәт күрсәтү оешмалары кирәк?

**1)** Төркия

**2)** Белоруссия

**3)** Нидерландлар

**4)** Дания

851. Туфракны җир эррозиясеннән сакларга нәрсә ярдәм итә?

**1)** кырларны саклый торган урман полосалары булдыру

**2)** тау битләрен сөрү

**3)** тау битләрендә хайван көтүләрен йөртү

**4)** сазлыклы җирләрне киптерү

852. Күп илләр өчен вулканнарның активлыгын күзәтү һәм атылачак янартаулар (вулканнар) турында хәбәр итү хезмәте булу актуаль булып тора. Түбәндә китерелгән илләрнең кайсы өчен янартау активлыгына даими күзәтү ясап тору актуаль?

**1)** Һиндстан

**2)** Мексика

**3)** Австралия

**4)** Бөекбритания

853. Хуҗалык эшчәнлеге төрләренең кайсы тирә-як мохиткә тискәре йогынты ясый?

1) карьерлар урынында җирне рекультивацияләү
2) файдалы казылмаларны ачык ысул белән чыгару
3) дала зоналарында кырларны саклагыч урман полосалары булдыру
4) йомык су әйләнеше системасын файдалану

854. Су басулар елга ярларында яшәүчеләргә шактый бәла-каза китерә. Түбәндә китерелгән елгаларның кайсысы елның теләсә кайсы вакытында һич көтмәгәндә ярларыннан ташып чыгарга сәләтле?

1) Печора
2) Дон
3) Идел
4) Кубань

855. Елганың үрге агымында (башында) сазлыкларны киптерү ... китерергә мөмкин.

1) су асты суларының күтәрелүенә
2) туфракта су эрозиясенең таралуына
3) елгаларның саегуына
4) елга суларын пычранудан саклауга

856. Чокыр кырыйларына агачлар һәм куаклар утырту ... китерергә мөмкин.

1) җирнең ныгуына
2) җил эрозиясе таралуга
3) чокырның үсешенә
4) су асты суларының кимүенә

857. Кар ишелмәләре - табигатьтәге иң куркыныч күренешләрнең берсе. Россиянең кайсы районында кар ишелмәләре аеруча зур куркыныч тудыра?

1) Калининград өлкәсендә
2) Кабардин-Балкар Республикасында
3) Марий Эл Республикасында
4) Архангельск өлкәсендә

858. Дала зонасында кыр ышыклау урман полосалары утыртканда,

1) туфракта дым күбрәк саклана.
2) үсемлекләрне тукландыра торган минераль элементларның юып чыгарылуы көчәя.
3) туфракта җил эрозиясе көчәя.
4) чокырлар күбрәк ясала.

859. Российнең төньяк регионнары кысаларында глобаль җылыну нәтиҗәсендә галимнәр тарафыннан фаразлана торган үзгәрешләргә ... кертергә мөмкин.

1) авыл хуҗалыгы культураларының уңыш бирүе кимүне
2) урман үсемлек дөньясы юкка чыгуны
3) көн озынлыгы артуны
4) күпьеллык туңның эрүен

860. Җир тетрәүләр һәм су астында вулкан атылу күренешләре белән чиксез зур диңгез дулкыннары – цунами барлыкка килү куркынычы арасында бәйләнеш бар. Бу үз чиратында яр буйларында урнашкан шәһәрләрне һәм башка төр торак пунктларны куркыныч астына куя. Түбәндә бирелгән илләрнең кайсында цунами якынлашуны кисәтә торган махсус хезмәт күрсәтелү ихтыяҗы зур?

1) Индонезиядә

**2)** Согут Гарәпстанында

**3)** Грециядә

**4)** Египетта

861. Су ресурсларын пычранудан саклауга ... ярдәм итә.

**1)** елга һәм күл яр буйларында су туплауга юнәлдерегән (водоёмкие) производстваларны урнаштыру

**2)** су туплауга юнәлдерегән (водоёмкие) производстваларда ябык су әйләнеше системасын булдыру

**3)** елгаларның башланган урыннарында сазлыкларны киптерү

**4)** елга үзәнлекләрендәге урманнарны кисү

862. Табигатьтән рациональ файдалануга мисал булып ... тора.

**1)** халык тыгыз урнашкан районнарда агулы калдыкларны күмү

**2)** ТЭСларны табигый газдан күмергә күчерү

**3)** кечкенә елгаларның башында сазлыкларны киптерү

| | |
|---|---|
| **4)** | сәнәгый предприятиеләрендә су әйләнешен тәэмин итү системасын булдыру |
| | |

---

863. Күп илләр өчен вулканнарның активлыгын күзәтү һәм атылачак янартаулар (вулканнар) турында хәбәр итү хезмәте булу актуаль булып тора. Түбәндә китерелгән илләрнең кайсы өчен янартау активлыгына даими күзәтү ясап тору актуаль?

**1)** Казахстан

**2)** Филиппин дәүләте

**3)** Австралия

**4)** Франция

864. ОАО «РусГидро» – «Волжская ГЭС» филиалында «Программа реализации экологической политики на 2012–2014 годы» исемле документ эшләнгән һәм расланган. Өч ел эчендә экологиягә 3,72 млрд сумнан артык акча биреләчәк. Төп мероприятияләр булып гидротехник корылмаларның ныклыгын, куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшләр торачак, 6 гидротурбина югары егәрлекле һәм яхшыртылган экологик характеристикалы яңа гидротурбинага алыштырылачак. Гидротурбинларның эшче көпчәкләрендәге тыгызлагычлар

алмаштырылачак, бу исә Идел елгасына машина мае агу ихтималын тулысынча юкка чыгарачак. Идел елгасының сул як ярын ныгытуны реконструкцияләү проекты эшләнәчәк, грунт плотиналары откосларының тимер-бетон ныгытмаларына агымдагы ремонт үткәреләчәк. Әлеге эшләр Идел елгасының сул яры җимерелүгә юл куймаячак.

Текстны укыгыз, Волжск ГЭСы китереп чыгарган, бу турыда текстта сүз алып барылган ике тискәре экологик нәтиҗәне күрсәтегез. Җавабыгызны аерым биткә языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

---

865. Россия Федерациясенең климатик доктринасында соңгы ун ел эчендә климатның глобаль җылыну тизлеге арту турында әйтелә. Санап кителгәннәрнең кайсысын шуның йогынтысында Россия территориясендә булырга мөмкин булган уңай нәтиҗәләр дип карарга мөмкин.

**1)** экстремаль атмосфера явым-төшемнәренең, су басуларның артуы; аерым регионнарда туфракның артык дымлануын

**2)** бозга бәйле хәлнең үзгәрүе, арктик шельфны үзләштерү шартларын үзгәртү

**3)** күпчелек торак пунктларда җәйге сезонда һаваны кондиционирлау өчен электр энергиясе сарыф ителү

артуны

**4)** төньяк регионнарда күпьеллык туңның корылмалар һәм коммуникацияләргә зыян китереп эрүен

866. Приморье краенда халыкны цунами якынлашып килүе турында кисәтү хезмәте эшли. Россиянең тагын кайсы территориясендә халыкны цунами якынлашып килүе турында кисәтү буенча махсус хезмәт кирәк?

**1)** Камчатка ярымутравында

**2)** Таймыр ярымутравында

**3)** Яңа Җир утравында

**4)** Новосибирск утрауларында

867. Бирелгән чараларның кайсы дала зонасында туфрак эрозиясе белән көрәштә файдаланыла?

**1)** тау битләрен сөрү

**2)** кырларны саклагыч урман  полосалары булдыру

3) елга буйларындагы үзәнлекләрдә сазлыкларны киптерү

4) химик мелиорация

868. Җир тетрәү куркынычы зур булган регионнарда җир тетрәүләргә каршы тора алырлык биналар төзергә кирәк. Санап кителгән регионнарның кайсында мондый биналар төзү ихтыяҗы зур?

1) Иваново өлкәсе

2) Коми Республикасы

3) Тамбов өлкәсе

4) Алтай Республикасы

869. Санап кителгәннәрнең кайсы “кислоталы” яңгырлар ясалуга китерергә мөмкин.

1) минераль ашламалар куллану

2) елга буйларындагы үзәнлекләрдә сазлыкларны киптерү

3) урманнарны кисү

**4)** бакыр эретү заводлары эшләп тору

870. Тау битләрендә чокырлар ясалмасын өчен ... кирәк.

**1)** агачлар һәм куаклар утырту

**2)** җирне сөрү

**3)** җил эрозиясе таралуга каршы тору

**4)** минераль ашламалар кулллануны чикләү

**5)** җирне сугару

871. Җир тетрәүләр һәм су астында вулкан атылу күренешләре белән чиксез зур диңгез дулкыннары – цунами барлыкка килү куркынычы арасында бәйләнеш бар. Бу үз чиратында яр буйларында урнашкан шәһәрләрне һәм башка төр торак пунктларны куркыныч астына куя. Түбәндә бирелгән территорияләрнең кайсында цунами якынлашуны кисәтә торган махсус хезмәт күрсәтелү ихтыяҗы зур?

**1)** Курил утраулары

**2)** Новосибирск утраулары

**3)** Яңа Җир утраулары

| | |
|---|---|
| **4)** | Төньяк Җир утраулары |
| | |

872. Россия Федерациясенең климатик доктринасында соңгы ун ел эчендә климатның глобаль җылыну тизлеге арту турында әйтелә. Санап кителгәннәрнең кайсысын шуның йогынтысында Россия территориясендә булырга мөмкин булган уңай нәтиҗәләр дип карарга мөмкин.

| | |
|---|---|
| 1) | Кайбер регионнарда корылыкның кабатлануы, ешлыгы һәм дәвамлылыгы. |
| 2) | Арктика диңгезләрендә бозга бәйле хәлнең һәм йөк ташу шартларының үзгәрүе. |
| 3) | Күпчелек торак пунктларда җәйге сезонда һаваны кондиционирлау өчен электр энергиясе сарыф ителү артуны. |
| 4) | Төньяк регионнарда күпьеллык туңның корылмалар һәм коммуникацияләргә зыян китереп эрүен. |
| | |

873. Россиянең төньяк регионнарында үткәргеч трубалар

(трубопровод) челтәрләрен (шул исәптән су белән тәэмин итү трубаларын) төзү һәм эксплуатацияләүнең төп проблемалары күпьеллык туңның киң территорияләрне алып торуына бәйле. Барлык үткәргеч трубаларны грунтның өстенә терәүләргә яки эстакадалар буйлап салырга кирәк, чөнки җәен грунт ике һәм аннан да тирәнрәк метрга эри. Россиянең кайсы регионында күпьеллык туңның эрүе китереп чыгарырга мөмкин булган нәтиҗәләрне исәпкә алырга кирәк?

1) Саха Республикасы (Якутия)
2) Киров өлкәсе
3) Вологодск өлкәсе
4) Карелия Республикасы

874. Җир тетрәүләр халыкны бәла-казага дучар итә. Халыкны махсус хезмәт күрсәтү оешмалары аша бу турыда кисәтү җир тетрәү китерергә мөмкин һәлакәтләрдән коткарып кала ала. Түбәндәге исемлектә китерелгән илләрнең кайсысына шундый махсус хезмәт күрсәтү оешмалары кирәк?

1) Индонезия
2) Финляндия

**3)** Нидерландлар

**4)** Польша

---

875. Кар ишелмәләре - табигатьтәге иң куркыныч күренешләрнең берсе. Россиянең кайсы районында кар ишелмәләре аеруча зур куркыныч тудыра?

**1)** Калининград өлкәсе

**2)** Төньяк Осетия Республикасы – Алания

**3)** Чуваш Республикасы

**4)** Архангельск өлкәсе

---

876. Табигатьтән рациональ файдаланмауның үрнәге булып, ... тора.

**1)** агач әзерләү, аның урынына яңасын утырту

**2)** макулатурадан кәгазь  ясау

**3)** алына торган чималны комплексды файдалану

**4)** тау битләрендәге җирләрне сөрү

877. Җир тетрәүләр һәм су астында вулкан атылу күренешләре белән чиксез зур диңгез дулкыннары – цунами барлыкка килү куркынычы арасында бәйләнеш бар. Бу үз чиратында яр буйларында урнашкан шәһәрләрне һәм башка төр торак пунктларны куркыныч астына куя. Түбәндә бирелгән территорияләрнең кайсында цунами якынлашуны кисәтә торган махсус хезмәт күрсәтелү ихтыяҗы зур?

**1)** Япония

**2)** Швеция

**3)** Испания

**4)** Алжир

878. Дала зонасында кыр ышыклау урман полосалары авыл хуҗалыгы файдалана торган җирләрне ... саклау өчен утыртыла.

**1)** биологик корткычлардан

**2)** кояшның артык көчле  радиациясеннән

**3)** җил эрозиясеннән

**4)** көчле кар явулардан

879. Күпьеллык туң кешенең файдалы казылмаларны чыгарып бетерү, юллар һәм биналар төзү кебек хуҗалык эшчәнлегенә йогынты ясый. Россиянең  кайсы регионында күпьеллык туң эрү китереп чыгару ихтималы булган нәтиҗәләрне исәпкә алырга кирәк?

**1)** Калининград өлкәсендә

**2)** Ростов  өлкәсендә

**3)** Оренбург өлкәсендә

**4)** Красноярск краенда

880. Елга суларын пычранудан саклауга ... ярдәм итә.

**1)** елга үзәннәрендәге урманнарны кисү

**2)** елга ярларында су җыюга бәйле производство урнаштыру

**3)** елга башларындагы сазлыкларны киптерү

**4)** елга бассейннарында ашламалар куллануны чикләү

---

881. Дала зонасында туфракны җил эрозиясеннән саклауга ... ярдәм итә.

**1)** куаклар һәм агачлар утырту

**2)** территорияләрне сөрү

**3)** карьерлар барлыкка китерү

**4)** көтү көтү

---

882. Җир тетрәүләр халыкны бәла-казага дучар итә. Халыкны махсус хезмәт күрсәтү оешмалары аша бу турыда кисәтү җир тетрәү китерергә мөмкин һәлакәтләрдән коткарып кала ала. Түбәндәге исемлектә китерелгән илләрнең кайсысына шундый махсус хезмәт күрсәтү оешмалары кирәк?

**1)** Австралия

**2)** Польша

**3)** Нидерландлар

**4)** Чили

883. Елга суларын пычранудан саклауга ... ярдәм итә.

**1)** елга бассейннарында минераль ашламаларны куллану

**2)** промышленность предприятияләрендә ябык су әйләнеше системасын булдыру

**3)** елга бассейннарындагы сазлыкларны киптерү

**4)** елга ярларында су җыюга бәйле производство урнаштыру

884. Күп илләр өчен вулканнарның активлыгын күзәтү һәм халыкка, атылачак янартаулар (вулканнар) турында хәбәр итү хезмәте булу актуаль булып тора. Түбәндә китерелгән илләрнең кайсы өчен янартау активлыгына даими күзәтү ясап тору актуаль?

**1)** Бөекбритания

**2)** Италия

**3)** Австралия

**4)** Германия

885. Корылык, коры җил һәм тузан давыллары кебек климатик күренешләр авыл хуҗалыгын алып баруны авырайталар. Санап кителгән территориянең кайсы өчен алар аеруча характерлы?

**1)** Мурманск өлкәсе

**2)** Вологодск өлкәсе

**3)** Коми Республикасы

**4)** Оренбург өлкәсе

886. Авыл хуҗалыгы культураларыннан мул уңыш алу өчен бик күп төрле табигый факторларны истә тотырга кирәк. Шуларның берсе – туфракның дымлылыгы дәрәҗәсе Россиянең кайсы регионында туфракта дымны саклауга юнәлдерелгән чараларны куллану аеруча мөһим.

**1)** Смоленск өлкәсе

**2)** Пермь крае

**3)** Новгород өлкәсе

**4)** Ставрополь крае

887. Күпьеллык туң, кешеләрнең хуҗалык итүенә көчле тәэсир итә. Туң нәтиҗәсендә күзәтелгән тискәре факторлардан тыш уңай факторлар да күзәтелә. Мисал өчен, күп еллар туң хәлендә булган җирне азык-төлек саклау өчен табигый туңдыргыч итеп файдаланалар. Россиянең кайсы регионнарында күп еллар туң хәлендә булган җирләрдә (грунтта) табигый туңдыргычлар ясарга мөмкин?

**1)** Пермь краенда

**2)** Чуваш Республикасында

**3)** Магадан өлкәсендә

**4)** Карелия Республикасында

888. Бирелгән территорияләрнең кайсысы өчен тропик циклоннар

аеруча зур куркыныч тудыра?

**1)** Балкан ярымутравы

**2)** Канар утраулары

**3)** Һинд - Кытай ярымутравы

**4)** Бөекбритания утравы

889. 2013 нче елга Калмыкиядә гомуми егәрлеге 300 МВт булган 50 җил-энегетик җайланмадан торган парк төзү планлаштырыла. Республика бер елга 150 МВт энергия тоткан очракта, бу электроэнергиянең резерв запасын алдан билгеләргә һәм артык энергияне күпләп сату базарында сатарга мөмкинлек тудыра. Җил-энергетик җайланманы урнаштыру урыны алдан ук климатик шартларны исәпкә алып билгеләнгән була.

Ни өчен Калмыкиядә электр энергиясе эшләп чыгару өчен җил җайланмалары паркы төзергә мөмкин? Калмыкиянең табигый-ресурс базасына бәйле тагын бер сәбәпне атагыз.

Җавабыгызны аерым биткә языгыз, башта биремнең номерын бирегез.

890. Табигатьтән рациональ файдаланмауның үрнәге булып, ... тора.

1) күмер чыгарыла торган районнарда җирне кабат культивацияләү

2) ТЭС ларда күмер урынына табигый газдан файдалану

3) агулы калдыкларны халык тыгыз яши торган районнарда күмү

4) алына торган чималны комплекслы файдалану

891. Корылык, коры җил һәм тузан давыллары кебек климатик күренешләр авыл хуҗалыгын алып баруны авырайталар. Санап кителгән территориянең кайсы өчен алар аеруча характерлы?

1) Псков өлкәсе

2) Карелия Республикасы

3) Камчатка крае

4) Волгоград өлкәсе

892. Климатта бара торган глобаль үзгәрешләр бозлыкларның капламнарының эрүенә һәм шуның нәтиҗәсе буларак, Дөнья

океанының биеклеге күтәрелүгә китерергә мөмкин. Шулай булган очракта Россиянең кайсы шәһәре аеруча зыян күрер?

1) Петрозаводск

2) Ставрополь

3) Санкт-Петербург

4) Екатеринбург

893. Табигатьтән рациональ файдаланмауның үрнәге булып, ... тора.

1) макулатурадан кәгазь ясау

2) су саклауга бәйле производстволарда су әйләнешенең ябык системасын барлыкка китерү

3) елга башланган урынарда сазлыкларны киптерү

4) күмер чыгарыла торган районнарда җирне кабат культивацияләү

894. Россиянең түбәндә китерелгән регионнарының кайсында климатик шартлар җил электроэнергииясеннән файдалану өчен

уңайлырак?

1) Калининград өлкәсендә

2) Байкал аръягы краенда

3) Хакасия Республикасында

4) Алтай краенда

895. Климатта бара торган глобаль үзгәрешләр бозлыкларның капламнарының эрүенә һәм шуның нәтиҗәсе буларак, Дөнья океанының биеклеге күтәрелүгә китерергә мөмкин. Шулай булган очракта Россиянең кайсы шәһәре аеруча зыян күрер?

1) Чита

2) Калининград

3) Владимир

4) Курск

896. Күп илләр өчен вулканнарның активлыгын күзәтү һәм халыкка атылачак янартаулар (вулканнар) турында хәбәр итү хезмәте актуаль булып тора. Түбәндә китерелгән илләрнең кайсы өчен янартау активлыгына даими күзәтү ясап тору актуаль?

1) Финляндия

2) Исландия

3) Египет

4) Австралия

897. Сил – кисәк кенә килеп чыга торган, җимергеч көчкә ия булган балчык яки ташлы балчык агымы. Россиянең кайсы районнарында силләр аеруча куркыныч?

1) Вологодск өлкәсе

2) Ямал-Ненец автономияле округы

3) Дагестан Республикасы

4) Воронеж өлкәсе

898. Цунами–яр буйларында яки диңгездәге җир тетрәүләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм бик зур тизлек белән берничә мең километрларга тарала торган гаять зур диңгез дулкыны. Гаҗәеп зур су валлары ярга китереп бәрәләр һәм зур

территорияләрне су астында калдыралар, биналарны, электр тапшыру линияләрен, күперләрне, юлларны җимерәләр. Россиянең кайсы территориясендә халыкны цунами куркынычы турында кисәтә торган хезмәт булдыру ихтыяҗы зур?

1) Ямал ярымутравы

2) Төньяк Җир архипелагы

3) Кола ярымутравы

4) Курил утраулары

899. Җир тетрәүләр һәм су астында вулкан атылу күренешләре белән чиксез зур диңгез дулкыннары – цунами барлыкка килү куркынычы арасында бәйләнеш бар. Бу үз чиратында яр буйларында урнашкан шәһәрләрне һәм башка төр торак пунктларны куркыныч астына куя. Түбәндә бирелгән территорияләрнең кайсында цунами якынлашуны кисәтә торган махсус хезмәт күрсәтелү ихтыяҗы зур?

1) Швеция

2) Болгария

3) Төркмәнстан

4) Филиппин дәүләте

901. Илебездә җир тетрәү куркынычы зур булган районнарда торак йортларны проектлау һәм төзүнең махсус кагыйдәләре бар. Түбәндә китерелгән регионнарның кайсында җир тетрәү куркынычы зур булу сәбәпле элеге кагыйдәләргә нигезләнергә кирәк?

**1)** Сахалин өлкәсе

**2)** Челябе өлкәсе

**3)** Коми Республикасы

**4)** Оренбург өлкәсе

902. Авыл хуҗалыгы культураларыннан мул уңыш алу өчен бик күп төрле табигый факторларны истә тотырга кирәк. Шуларның берсе – явым–төшемнәрнең күләме, ул туфракның дымлылыгына тәэсир итә торган төп фактор санала. Россиянең кайсы регионында туфракта дымны саклауга юнәлдерелгән чараларны куллану аеруча мөһим?

**1)** Томск өлкәсе

**2)** Ставрополь крае

**3)** Псков өлкәсе

**4)** Пермь крае

903. Санап кителгән бетеп бара табигый ресурсларның кайсын яңадан торгызырга була?

**1)** таш күмер

**2)** бакыр рудасы

**3)** җил энергиясе

**4)** урман ресурслары

---

904. Җир тетрәүләр һәм су астында вулкан атылу күренешләре белән чиксез зур диңгез дулкыннары – цунами барлыкка килү куркынычы арасында бәйләнеш бар. Бу үз чиратында яр буйларында урнашкан шәһәрләрне һәм башка төр торак пунткларны куркыныч астына куя. Түбәндә бирелгән территорияләрнең кайсында цунами якынлашуны кисәтә торган махсус хезмәт күрсәтелү ихтыяҗы зур?

**1)** Чукотка ярымутравы

2) Кола ярымутравы

3) Курил утраулары

4) Яңа Җир архипелагы

905. Корылык, коры җил һәм тузан давыллары кебек климатик күренешләр авыл хуҗалыгын алып баруны авырайталар. Санап кителгән территориянең кайсы өчен алар аеруча характерлы?

1) Киров өлкәсе

2) Камчатка крае

3) Астрахань өлкәсе

4) Коми Республикасы

906. Корылык, коры җил һәм тузан давыллары кебек климатик күренешләр территорияне хуҗалык эшләрендә файдалануны авырайталар. Санап кителгән территориянең кайсы өчен алар аеруча характерлы?

1) Калмык Республикасы

**2)** Пермь крае

**3)** Хабаровск  крае

**4)** Карелия Республикасы

---

907. Бетеп бара торган әлеге табигый ресурсларның кайсын яңадан торгызырга була?

**1)** җил энергиясен

**2)** туфракның уңдырышлылыгын

**3)** таш күмерне

**4)** кояш энергиясен

---

908. Тропик  циклоннар  гаять зур энергиягә ия һәм   катастрофик җимерүләргә   китерүгә  сәләтле.  Түбәндә  бирелгән  кайсы  илдә  яшәүчеләр өчен   тропик  циклоннар аеруча куркыныч?

**1)** Бангладеш

**2)** Нигер

**3)** Испания

**4)** Төркия

909. Күпьеллык туң кешенең файдалы казылмалар чыгару, юллар һәм биналар төзү кебек хуҗалык эшләренә йогынты ясый. Россиянең кайсы регионында күпьеллык туң эрү китереп чыгарырга мөмкин булган нәтиҗәләрне исәпкә алырга кирәк?

**1)** Ульяновск

**2)** Новгород

**3)** Свердловск

**4)** Магадан

910. Җир тетрәүләр һәм су астында вулкан атылу күренешләре белән чиксез зур диңгез дулкыннары – цунами барлыкка килү куркынычы арасында бәйләнеш бар. Бу үз чиратында яр буйларында урнашкан шәһәрләрне һәм башка төр торак пунктларны куркыныч астына куя. Түбәндә бирелгән территорияләрнең кайсында цунами якынлашуны кисәтә торган

махсус хезмәт күрсәтелү ихтыяҗы зур?

**1)** Байкал аръягы (Забайкальски) крае

**2)** Ямал-Ненец АО

**3)** Приморье крае

**4)** Архангельск өлкәсе

911. Санап кителгәннәрнең кайсы елгалар саегуга сәбәп булырга мөмкин?

**1)** елга аша күпер төзү

**2)** елга бассейнында тыюлык төзү

**3)** елга бассейнындагы елгаларны сугару

**4)** елга башындагы сазлыкларны киптерү

912. Табигатьтән рациональ файдаланмауның үрнәге булып, ... тора.

**1)** күмер чыгарыла торган районнарда җирне кабат

культивацияләү

2) алына торган чималны комплекслы файдалану

3) агач әзерләүне урманнар утырту белән бергә алып бару

4) елгалар буйлап бүрәнәләп урман агызу

913. Җир тетрәүләр бәла-каза китерә, бу күренеш аеруча таулы урыннарда яшәүчеләргә зыян сала. Әлеге күренеш санап кителгән территорияләрнең кайсында күзәтелә?

1) Вологод өлкәсендә

2) Ямал-Ненец автономияле округы

3) Дагыстан Республикасында

4) Смоленск өлкәсендә

914. Климатның глобаль җылынуы Антарктида бозлыкларының капламнары эрүгә һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, Дөнья океанының биеклеге күтәрелүгә китерергә мөмкин. Шулай булган очракта, Россиянең кайсы шәһәре аеруча зыян күрер?

1) Санкт-Петербург

2) Уфа

3) Ставрополь

4) Екатеринбург

---

915. Сейсмиклык –хуҗалык эшчәнлегенең теләсә кайсы төрен башкарганда, шул исәптән төзелеш эшләре башкарганда, исәпкә алына торган фактор. Россиянең санап кителгән регионнарының кайсында җир тетрәүләр күзәтелә һәм төзелештә биналарның җир тетрәүләргә каршы тора алуын күтәрә торган технологияләр кулланыла?

1) Оренбург өлкәсендә

2) Архангельск өлкәсендә

3) Самара өлкәсендә

4) Сахалин өлкәсендә

---

916. Җир тетрәүләр һәм су астында вулкан атылу күренешләре

белән чиксез зур диңгез дулкыннары – цунами барлыкка килү куркынычы арасында бәйләнеш бар. Бу үз чиратында яр буйларында урнашкан шәһәрләрне һәм башка төр торак пунктларны куркыныч астына куя. Түбәндә бирелгән территорияләрнең кайсында цунами якынлашуны кисәтә торган махсус хезмәт күрсәтелү ихтыяҗы зур?

1) Бөекбритания

2) Индонезия

3) Бразилия

4) Египет

917. Кар ишелмәләре - табигатьтәге иң куркыныч күренешләрнең берсе. Россиянең кайсы районында кар ишелмәләре аеруча зур куркыныч тудыра?

1) Төньяк Осетия Республикасы – Алания

2) Омск өлкәсе

3) Ямал-Ненец АО

4) Тула өлкәсе

918. Сазлыклар күп булу объектларны төзүне авырайта һәм кыйммәтләндерә. Россиянең регионында сазлыклар, сазлык җирләрнең мәйданы аеруча зур?

1) Көнбатыш Себер тигезлеге
2) Урта Рус калкулыгы
3) Идел буе калкулыгы
4) Каспий буе түбәнлеге

919. Сейсмиклык –хуҗалык эшчәнлегенең теләсә кайсы төрен башкарганда, шул исәптән төзелеш эшләре башкарганда, исәпкә алына торган фактор. Россиянең санап кителгән регионнарының кайсында җир тетрәүләр күзәтелә һәм төзелештә биналарның җир тетрәүләргә каршы тора алуын күтәрә торган технологияләр кулланыла?

1) Сахалин өлкәсе
2) Ненец автономияле округы
3) Марий Эл Республикасы
4) Архангельск өлкәсе

920. Су басу елга буйларында яшәүче кешеләргә бик күп бәла-каза китерә. Санап кителгән елгаларның кайсында җәйге чорда су басулар ешрак була?

1) Амур

2) Идел

3) Дон

4) Кама

921. Җир тетрәү иң куркыныч табигать күренешләренең берсе. Җир тетрәү нәтиҗәсендә елгаларның юллары үзгәрә, биналар, корылмалар җимерелә. Россия регионнарының кайсында җир тетрәү булу ихтималын истә тотырга кирәк?

1) Әстерхан өлкәсендә

2) Смоленск өлкәсендә

3) Ленинград өлкәсендә

4) Сахалин өлкәсендә

922. Климатның глобаль җылынуы, Дөнья океанының биеклеге күтәрелүгә һәм шуның нәтиҗәсендә кайбер илләрнең территорияләре су астында калырга мөмкин. Санап кителгән илләрнең кайсының бер өлеш территориясе су астында калырга мөмкин?

1) Австрия

2) Франция

3) Словакия

4) Әфганстан

923. Түбәндә китерелгән чараларның кайсы файдалана торган җирләрнең продуктивлыгын күтәрүгә китерә ала?

1) урманнар утырту

2) файдалы казылмаларны ачык ысул белән чыгара торган урыннарда терриконнар булдыру

3) корылык була торган районнарны ясалма сугару

4) тау битләрендәге җирләрне сөрү

924. Дала зоналары табигатеннән рациональ файдалану булып ... тора.

**1)** кышкы чорда кар тотулар үткәрү

**2)** елгаларның башланган урыннарында сазлыкларны киптерү

**3)** калкулык урыннардагы тау битләрен сөрү

**4)** ачык ысул белән тимер рудасы чыгару

925. Су ресурсларын пычранудан саклауга ... ярдәм итә.

1) елга һәм күл ярларына су җыюлы производстволарны урнаштыру

2) промышленность предприятияләрендә ябык су әйләнеше системасын булдыру

3) елга башланган җирләрдәге сазлыкларны киптерү

4) кар суларын эре сусаклагычларга җыю

926. Кайсы газ атмосфера һавасы составында артып киткәндә, «парник эффекты» көчәю күзәтелә?

1) кислород
2) водород
3) метан
4) азот

927. Бирелгән һәм бетеп баруга йөз тоткан табигый ресурсларның яңадан торгызып булмый торганы кайсы?

1) таш күмер
2) урман ресурслары
3) туфрак ресурслары
4) су килү энергиясе (приливов)

928. Хуҗалык эшчәнлегенә мисал белән шуңа бәйле табигатьтән файдалану тибы арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз. Сайлап алынган элементларның номерларын таблицага туры килгән хәрефләре астына языгыз.

| **МИСАЛ ХУҖАЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕ** | | **ТИП ТАБИГАТЬТӘН ФАЙДАЛАНУ** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | елгаларның башланган урыннарында сазлыкларны киптерү | **1)** | рациональ |
| **Б)** | табыла торган чималдан комплекслы файдалану | **2)** | рациональ булмаган |
| **В)** | дала зоналарында урман полосалары утырту | | |

929. Хуҗалык эшчәнлегенә мисал белән шуңа бәйле табигатьтән файдалану тибы арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз. Сайлап алынган элементларның номерларын таблицага туры килгән хәрефләре астына языгыз.

| **ХУҖАЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ МИСАЛ** | **ТАБИГАТЬТӘН ФАЙДАЛАНУ ТИБЫ** |
|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| А) | корылык була торган районнарны кирәгеннән артык сугару | 1) | рациональ |
| Б) | табыла торган чималдан комплекслы файдалану | 2) | рациональ булмаган |
| В) | ачык ысул белән файдалы казылмалар чыгару | | |

930. Хуҗалык эшчәнлегенә мисал белән шуңа бәйле табигатьтән файдалану тибы арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз. Сайлап алынган элементларның номерларын таблицага туры килгән хәрефләре астына языгыз.

| **<u>ХУҖАЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ МИСАЛ</u>** | | **<u>ТАБИГАТЬТӘН ФАЙДАЛАНУ ТИБЫ</u>** | |
|---|---|---|---|
| А) | елгаларның башланган урыннарында сазлыкларны киптерү | 1) | рациональ |
| | | 2) | рациональ булмаган |

| | |
|---|---|
| **Б)** | күмер чыгарыла торган районнардагы җирләрне яңадан культивацияләү |
| **В)** | далада урманнарны саклау полосалары булдыру |

931. Һәр табигый ресурс белән белән ул караган төре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз. Сайлап алынган элементларның номерларын таблицага туры килгән хәрефләре астына языгыз.

| **ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ** | | **ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫНЫҢ ТӨРЛӘРЕ** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | урман | **1)** | тотып бетерелә – торгызып була торган |
| **Б)** | җил энергиясе | **2)** | тотып бетерелә – торгызып булмый торган |
| **В)** | табигый газ | **3)** | тотып бетерелми торган |

932. Хуҗалык эшчәнлегенә мисал белән шуңа бәйле табигатьтән файдалану тибы арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз. Сайлап алынган элементларның номерларын таблицага туры килгән хәрефләре астына языгыз.

| **ХУҖАЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ МИСАЛ** | | **ТАБИГАТЬТӘН ФАЙДАЛАНУ ТИБЫ** |
|---|---|---|
| **А)** | икенчел чималдан файдалану | 1) рациональ |
| **Б)** | күмер чыгарыла торган районнардагы җирләрне яңадан культивацияләү | **2)** рациональ булмаган |
| **В)** | елгаларның башланган урыннарында сазлыкларны киптерү | |

933. Хуҗалык эшчәнлегенә мисал белән шуңа бәйле табигатьтән файдалану тибы арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз. Сайлап алынган элементларның номерларын таблицага туры килгән хәрефләре астына языгыз.

| **ХУҖАЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ МИСАЛ** | | **ТАБИГАТЬТӘН ФАЙДАЛАНУ ТИБЫ** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | тау һәм калкулык сыртлары буйлап җирләрне сөрү | **1)** | рациональ булмаган |
| **Б)** | табылган чималдан комплекслы файдалану | **2)** | рациональ |
| **В)** | металлоломны металлургиядә чимал буларак файдалану | | |

934. Һәр табигый ресурс һәм ул караган табигый ресурсларның төре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз. Сайлап алынган элементларның номерларын таблицага туры килгән хәрефләре астына языгыз.

| ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР | | ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАРНЫҢ ТӨРЛӘРЕ | |
|---|---|---|---|
| **А)** | нефть | **1)** | тотып бетерелә – торгызып була торган |
| **Б)** | Кояш энергиясе | **2)** | тотып бетерелми торган |
| **В)** | урман | **3)** | тотып бетерелә – торгызып булмый торган |

935. Һәр табигый ресурс һәм ул караган табигый ресурсларның төре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз.

Беренче баганадагы һәр элементка икенче баганадан туры килә торган элемент сайлап алыгыз. Сайлап алынган элементларның номерларын таблицага туры килгән хәрефләре астына языгыз.

| ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР | | ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАРНЫҢ ТӨРЛӘРЕ | |
|---|---|---|---|
| **А)** | җил энергиясе | **1)** | тотып бетерелми торган |
| **Б)** | таш күмер | **2)** | тотып бетерелә – торгызып була торган |
| **В)** | туфракка бәйле | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ресурслар | 3) | тотып бетерелә – торгызып булмый торган |

936. Күпьеллык туң кешенең файдалы казылмалар чыгару, юллар һәм биналар төзү кебек хуҗалык эшләренә йогынты ясый. Россиянең кайсы регионында күпьеллык туң эрү китереп чыгарырга мөмкин булган нәтиҗәләрне исәпкә алырга кирәк?

**1)** Тамбов өлкәсе

**2)** Татарстан Республикасы

**3)** Ростов өлкәсе

**4)** Магадан өлкәсе

937. Бирелгән табигый ресурсларның кайсы тотып бетерелә һәм торгызып булмый торган?

**1)** төче су

**2)** туфракның табигый уңдырышлылыгы

**3)** тоз

**4)** нефть

---

938. Дөньяның күп кенә илләре җир тетрәү куркынычы янаган районнарда урнашкан. Бу илләр өчен җир тетрәүләрне алдан прогнозлау һәм җир тетрәүгә чыдам биналар һәм корылмалар төзү аеруча әһәмиятле булып тора. Түбәндә бирелгән илләрнең кайсында җимергеч җир тетрәү ихтималлыгы зуррак?

**1)** Мексика

**2)** Финляндия

**3)** Австралия

**4)** Белоруссия

---

939. России МЧСы һәр ел өчен гадәттән тыш ситуацияләрнең прогнозын төзегәндә, Россиянең океан һәм диңгез яр буйларының цунами дулкыннары тарафыннан китерелергә мөмкин зыянны бәяли. Россиянең кайсы регионы халыклары өчен мондый прогнозлар аеруча мөһим?

1) Краснодар крае

2) Мурманск өлкәсе

3) Сахалин өлкәсе

4) Ленинград өлкәсе

940. Дөньяның күп кенә илләре җир тетрәү куркынычы янаган районнарда урнашкан. Бу илләр өчен җир тетрәүләрне алдан прогнозлау һәм җир тетрәүгә чыдам төзелеш аеруча әһәмиятле булып тора. Түбәндә бирелгән илләрнең кайсында җимергеч җир тетрәү ихтималлыгы зуррак?

1) Индонезия

2) Финляндия

3) Польша

4) Германия

941. Корылык, коры җил һәм тузан давыллары кебек климатик күренешләр авыл хуҗалыгы эшләрен алып баруны кыенайталар.

Санап кителгән территориянең кайсы өчен алар аеруча характерлы?

**1)** Калининград өлкәсе

**2)** Тверь өлкәсе

**3)** Карелия Республикасы

**4)** Оренбург өлкәсе

---

942. Табигатьтән рациональ файдалану булып ... тора.

**1)** калку җирләрдәге сыртларны сөрү

**2)** җил һәм кояш энергетикасы арту

**3)** агулы калдыкларны эре шәһәрләр янында күмү

**4)** кече елгаларның башларындагы сазлыкларны киптерү

943. Бирелгән ресурсларның кайсы сарыф итеп бетерелә – торгызып була торганнар исәбенә карый?

**1)** Кояш энергиясе

2) җил энергиясе

3) таш күмер

4) урман ресурслары

944. Җир тетрәү куркынычы булган районнарда кешеләрнең куркынычсызлыклары өчен төзелешнең аерым бер технологиясе кулланыла. Китерелгән регионнарның кайсында җир тетрәүгә чыдам төзелеш алып барырга кирәк?

1) Алтай Республикасында

2) Коми Республикасында

3) Омск өлкәсендә

4) Төмән өлкәсендә

945. Кар ишелмәләре - табигатьтәге иң куркыныч күренешләрнең берсе. Россия МЧС гадәттән тыш ситуацияләргә прогноз ясаганда, аерым регионнар өчен кар ишелмәләре тудырырга мөмкин булган куркынычны бәяли. Россиянең кайсы регионында яшәүчеләр өчен мондый прогнозлар бик мөһим?

1) Алтай Республикасы

2) Коми Республикасы

3) Киров өлкәсе

4) Новосибирск  өлкәсе

---

946. “Кислоталы яңгырлар”  («кислотные дожди») барлыкка килү сәбәпләренең берсе  булып ... тора.

1) корылык хас районнарны кирәгеннән артык сугару

2) елга башларындагы сазлыкларны киптерү

3) урман мәйданнары кыскару

4) металлургия  предприятияләре эшләү

---

947. Бирелгән ресурсларның кайсы сарыф итеп бетерелә – торгызып була торганнар исәбенә карый?

1) таш күмер

2) туфракның уңдырышлылыгы

**3)** җил энергиясе

**4)** кояш энергиясе

948. Атмосфераның газ составындагы нинди үзгәрешне атмосферада парник эффекты көчәюгә сәбәпче дип саныйлар?

**1)** азотның азаюын

**2)** озонның азаюын

**3)** углекислый газның артуын

**4)** кислородның артуын

949. Авыл хуҗалыгы культураларының уңышы туфракны дым белән баетучы явым-төшемнәрнең муллыгына бәйле**.** Россиянең кайсы регионында туфракта дым саклауга ярдәм итә торган чараларны куллану мөһим?

**1)** Архангельски өлкәсендә

**2)** Ставрополь краенда

**3)** Псков өлкәсендә

**4)** Пермь краенда

---

950. Ягулыкның кайсы төрен яндырганда, атмосфераны пычрата торган матдәләр азрак бүленеп чыга?

**1)** таш күмер

**2)** мазут

**3)** табигый газ

**4)** торф

951. Галимнәр климаттагы глобаль үзгәрешләр нәтиҗәсендә Дөнья океаны күтәрелергә мөмкин дип саныйлар. Шулай була калса, Россиянең кайсы шәһәре аеруча зыян күрергә мөмкин?

**1)** Әстерхан

**2)** Санкт-Петербург

**3)** Новосибирск

**4)** Челябинск

952. Әйләнә-тирә мохиткә ... тискәре йогынты ясый.

1) кырларда кар тоту үткәрү
2) дала зонасында урман полосасы булдыру
3) ТЭСларны күмердән табигый газга күчерү
4) тигезлек елгаларында ГЭС лар төзү

953. Атмосферага пычраткыч матдәләрне чыгаруны киметүгә ... китерә.

1) халык аз яши торган районнарда яңа ГРЭСлар төзү
2) нефть газын яндыру
3) җил һәм кояш электроэнергетикасы үсеше
4) җылылык электростанцияләрен табигый газдан күмергә күчерү

954. Убылу процесслары илебез территориясенең аерым өлешләре рельефына сизелерлек йогынты ясыйлар. Россиянең кайсы регионы территориясендә убылулар булу ихтималы зуррак?

1) Псков өлкәсе

2) Алтай Республикасы

3) Калмык Республикасы

4) Әстерхан өлкәсе

955. Су басулар елга яр буйларында яшәүчеләргә күп бәла-каза китерә. Түбәндә китерелгән елгаларның кайсына җил куып китергән күренешләргә бәйле су басулар характерлы?

1) Ангара

2) Иртыш

3) Кама

4) Нева

956. Су басулар елга яр буйларында яшәүчеләргә  күп бәла-каза китерә.  Түбәндә китерелгән елгаларның кайсында  су басулар нигездә җәй көне күзәтелә?

1) Амур
2) Дон
3) Идел
4) Кама

957. Кар ишелмәләре  - табигатьтәге иң куркыныч күренешләрнең берсе. Россия МЧСы  гадәттән тыш ситуацияләргә прогноз ясаганда, Россиянең океан һәм диңгез яр буйларына цунами дулкыннары зарар салу ихтималын бәяли. Россиянең кайсы регионындаяшәүчеләр өчен мондый прогнозлар бик мөһим?

1) Калининград өлкәсе
2) Ленинград  өлкәсе
3) Камчатка  крае
4) Ставрополь  крае

958. Газларның кайсы парник эффекты тудыра?

**1)** водород

**2)** метан

**3)** кислород

**4)** азот

c16673

959. Санап кителгән ресурсларның кайсылары яңартылып була торган энергия чыганагы?

**1)** нефть

**2)** елгалар гидроэнергиясе

**3)** кайнар сланцлар

**4)** ташкүмер

960. Табигатьтән рациональ файдалануга мисал булып ... тора.

**1)** калкулыклардага сөзәклекләрне сөрү

2) күмер чыгара торган урыннарда терриконнар барлыкка китерү

3) кояш һәм җил энергетикасын үстерү

4) кечкенә елгаларның башларында сазлыкларны киптерү

---

961. Атмосферада газ составындагы нинди үзгәрешне парник эффекты көчәюгә сәбәбче дип саныйлар?

1) азот артуны

2) метан артуны

3) кислород кимүне

4) озон кимүне

---

962. Кар ишелмәләре (лавиналары) - табигатьтәге иң куркыныч күренешләрнең берсе. Россия МЧСы гадәттән тыш ситуацияләргә прогноз ясаганда, Россиянең аерым регионнарында кар ишелмәләре тудыра торган куркынычны бәяли. Россиянең кайсы регионында яшәүчеләр өчен мондый прогнозлар бик

мөһим?

1) Алтай Республикасында

2) Воронеж өлкәсендә

3) Киров өлкәсендә

4) Коми Республикасында

963. Парник эффекты көчәюне атмосферада ... артуы сәбәбче була.

1) азотның

2) водородның

3) кислородның

4) углекислый газның

964. Елгаларның пычрануын киметү өчен

1) алар тирәсендәге кырларда кар тотулар үткәрергә кирәк.

2) елга ярларында су туплый торган производство булдырырга кирәк.

**3)** бассейннарында минераль ашламалар куллануны чикләргә кирәк.

**4)** елга башларында сазлыкларны киптерергә кирәк.

965. Җирдә (грунтта) күпьеллык туң яткан районнарда, корылмаларның ныклыгын тәэмин итү һәм аларны җимерелүдән саклау өчен, йортларны тирәнгә кагылган свайлар өстендә төзиләр. Россиянең кайсы шәһәрләрендә төзүнең шушы технологиясен файдаланырга кирәк?

**1)** Сыктывкарда

**2)** Новосибирскида

**3)** Томскида

**4)** Якутскида

966. Россиядәге кайсы шәһәрнең һава бассейнына ел саен иң күп күләмдәге пычраткыч матдәләр чыгарып ташлана?

**1)** Белгород

**2)** Орёл

**3)** Норильск

**4)** Ростов-Дон

---

967. Җир тетрәүләр куркынычы булган районнарда кешеләрнең куркынычсызлыгы өчен төзелешнең аерым бер технологиясе кулланыла. Бирелгән регионнарның кайсында җир тетрәүләргә каршы тора ала торган төзелеш алып барыла?

**1)** Карелия Республикасы

**2)** Мурманск өлкәсе

**3)** Новосибирск өлкәсе

**4)** Алтай Республикасы

---

968. Табигатьтән рациональ файдалануга мисал булып ... тора.

**1)** Кузбасста күмер чыгарыла торган урыннардагы җирләрне

кабат культивацияләү

2) КМАда ачык ысул белән тимер рудасы чыгару

3) Иделдәге ГЭС та каскад төзү

4) Идел елгасының башында сазлыкларны киптерү

969. Түбәндә бирелгән илләрнең кайсында стихияләр китереп чыгарган бәла-казалар аның территориясендә халыкның тыгыз урнашуы сәбәпле, аеруча зур куркыныч тудыралар.

1) Австралия

2) Бангладеш

3) Монголия

4) Согуд Гарәбестаны

970. Җирдә (грунтта) күпьеллык туң яткан районнарда, корылмаларның ныклыгын тәэмин итү һәм аларны җимерелүдән саклау өчен, йортларны тирәнгә кагылган свайлар өстендә төзиләр. Россиянең кайсы шәһәрләрендә төзүнең шушы технологиясен файдаланырга кирәк?

1) Петрозаводск

2) Магадан

3) Сыктывкар

4) Төмән

971. Россиядәге кайсы шәһәрнең һава бассейнына ел саен иң күп күләмдәге пычраткыч матдәләр чыгарып ташлана?

1) Краснодар

2) Калининград

3) Новокузнецк

4) Иваново

972. Климаттагы глобаль үзгәрешләр бозлыкларның өслеге эрүгә китерергә һәм шуның нәтиҗәсе буларак Дөнья океаны күтәрелергә мөмкин дип саныйлар. Шулай була калса, Россиянең кайсы шәһәре аеруча зыян күрергә мөмкин?

1) Екатеринбург

2) Тула

**3)** Архангельск

**4)** Төмән

973. Россия территориясендә җимергеч җир тетрәүләр ихтималы зур булган районнарның күп булу, анда сейсмик активлыкны фаразлауны һәм җир тетрәү куркынычы булган зоналарда төзелеш алып бару юнәлешендә махсус чаралар эшләп чыгаруны дәүләт игътибарының иң мөһим объектларының берсе буларак билгели. Россиянең кайсы регионында җир тетрәүләргә чыдамлыгы югары булган төзелеш алып барырга кирәк?

**1)** Тыва Республикасы

**2)** Коми Республикасы

**3)** Пенза өлкәсе

**4)** Астрахань өлкәсе

974. Кар ишелмәләре - табигатьтәге иң куркыныч күренешләрнең берсе. Россиянең кайсы регионында кар ишелмәләре аеруча зур куркыныч тудыра?

1) Ямал-Ненец автономияое округында

2) Карачай –Черкес  Республикасында

3) Әстерахан өлкәсендә

4) Калининград өлкәсендә

975. Туфрактагы су  эрозиясе авыл хуҗалыгына зур зыян сала. Эрозия  процессларын булдырмау һәм акырынайту өчен агып җыела торган суларны сөрүле җирләрдә тоткарлауга китерә торган чаралар  куллану мөһим. Үсемлекләр өчен кирәк булган дымны шулай саклау суның җирне, туфракны юудыруын  туктата. На территории какого из перечисленных Россиянең кайсы  регионы территориясендә туфракны су эрозиясеннән саклауга юнәлдерелгән чаралар үткәрү мөһим?

1) Псков өлкәсе

2) Краснодар крае

3) Ханты-Манси автономияле округы – Югра

4) Архангельск өлкәсе

976. Көчле җир тетрәүләр ихтималы зур булган Россия регионнарының кайсында җир тетрәүгә чыдам төзелеш алып барырга кирәк?

1) Алтай Республикасында
2) Карелия Республикасында
3) Томск өлкәсендә
4) Пермь краенда

977. Игенчелек белән шөгыльләнүче районнарда түбәндә китерелгән чараларның кайсысы туфракта эрозия артуга китерә?

1) сөзәк җирләрне даими сөрү
2) сөзәклекләрдән ясалма рәвештә үзгәртеп, чәчү җирләре ясау
3) басу араларына урман полосалары утырту
4) бөртеклеләрне алдан сөрмичә чәчү

978. Кайсы чара туфракны эрозиядән саклый?

**1)** сөзәк җирләрне даими сөрү

**2)** көтү кертү

**3)** бөртеклеләрне алдан сөрмичә чәчү

**4)** табигый үсемлек дөньясын юк итү

979. Санап кителгәннәрнең кайсы чокырлар ясалуга сәбәп була алмый?

**1)** сөзәклекләрдәге агачларны кисү

**2)** сөзәк җирләрне аркылыга сукалау

**3)** күпьеллык үләннәр утырту

**4)** ачык ысул белән руда файдалы казылмалар чыгару

980. «Парник эффект»ы – планета чыгарган җылылыкның Җир атмосферасында тоткарлануы. Атмосферада санап кителгән кайсы газның артык булуы «парник эффект» көчәюгә китерә?

1) кислородның

2) азотның

3) озонның

4) углекислый газның

981. Табигый ресурсларны рациональ файдаланмауга мисал булып ... тора.

1) чыгарыла торган файдалы казылмаларны тулысынча файдалану

2) нефть чыгарыла торган районнарда нефть газын факеллар итеп яндыру

3) әйләнешле су белән тәэмин ителеш системасын булдыру

4) производство калдыкларын эшкәртү системасын үстерү

982. Россиядә табигый ресурсларны рациональ файдалануга нәрсә комачаулый?

| | |
|---|---|
| **1)** | ил икътисады структурасында табыш китерү өлкәләренең артуы |
| **2)** | производство калдыкларын эшкәртү системасының үсеше |
| **3)** | фәнни казанышларга нигезләнгән югары технологияле производство булдыру |
| **4)** | аеруча саклана торган табигый территорияләр булдыру һәм үстерү |

983. Таблицадан файдаланып, 2010 нчы елдагы күчмә чыганаклардан атмосферага ташлана торган пычратучы матдәләрнең күләмен (өлешен) % ларда билгеләгез. Алынган нәтиҗәне бөтен сан итеп түгәрәкләгез.

**2010 нчы елда (мең тонна) күчмә һәм стационар чыганакларның атмосфераны пычрата торган матдәләрне ыргытуы**

| | |
|---|---|
| **атмосфераны пычрата торган матдәләр ыргытылган – барлыгы -** | 32 353 |
| шул исәптән: | |
| пычрата торган стационар чыганаклар | 19 116 |
| күчмә чыганаклар | 13 237 |

984. Мутновск геотермаль чыганакта ике геотермаль электростанция төзелә: Югары-Мутновск ГеоЭС һәм Мутновск ГеоЭС. Бу ГеоЭСларның гомуми егәрлеге 62 МВт. Алар Мутновск вулканыннан төньяк-көнчыгышта диңгез өслегеннән 780 Петропавловск-Камчатскадан 116 км чакырымда урнашканнар. Геотермаль энергетиканың үсеше – регион энергетикасы үсешенең мөһим өлеше, әлегә регионда электроэнергиянең 68% ын мазутта эшли торган ТЭЦлар бирә.

Геотермаль электростанциянең мазутта эшли торган ТЭСлардан экология ягыннан чыгып караганда нинди өстенлекләре бар? Ике өстенлеген күрсәтегез.

Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремнең номерын языгыз.

985. Дөньядагы иң борынгы паркларның берсе саналган Йеллоустон милли паркы – чын мәгънәсендә табигатьнең геологик могҗизасы ул. Монда ылыслы урманнар белән капланган биек таулар арасында бай үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының искиткеч ярашуы, тылсымлы табигать күренешләре кайнар су

чыганаклары, кайнар су һәм парны берничә дистә метр югарылыкка аттыра торган фонтаннар, миллион еллар элек үлгән агачларның оригиналлары булган ташка әйләнгән агачлар очратасың.

Милли паркларның нинди максат белән төзелүен аңлатыгыз. Ике максатны күрсәтегез.

Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремнең номерын языгыз.

986. Россиядә халык санының үзгәрүе (кеше)

| | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел |
|---|---|---|---|---|
| Халыкның бер елда гомуми үсеше | 31 927 | 191 032 | 319 825 | 305 469 |
| Халыкның бер елда табигый үсеше | –129 092 | –4312 | 24 011 | 35 433 |

2014 нче елда халыкның миграцион үсешен билгеләгез. Җавабыгызны саннарда чагылдырыгыз.

987. Россиядә ничәнче елда туучылар саны үлүчеләр санынан зуррак булган?

1) 2011 ел

2) 2012 ел

3) 2013 ел

4) 2014 ел

988. Белгород өлкәсе халкының саны үзгәрү (кеше)

| | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел |
|---|---|---|---|---|
| Халык санының бер елда гомуми үсеше | 3720 | 4912 | 3123 | 3828 |
| Халык санының бер елда табигый үсеше | –4630 | –3679 | –3443 | –3763 |

2014 елда Белгород өлкәсе халкының миграцион үсешен билгеләгез. Җавабыгызны саннарда чагылдырыгыз.

989. Ничәнче елда Белгород өлкәсендә үлүчеләр саны туучылар саныннан күбрәк булган?

1) 2011 ел

2) 2012 ел

**3)** 2013 ел

**4)** 2014 ел

990. Брянск өлкәсендә халык саны үзгәрү (кеше)

| | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел |
|---|---|---|---|---|
| Халык санының бер елда гомуми үсеше | –10 938 | –10 750 | –11 067 | –9659 |
| Халык санының бер елда табигый үсеше | –6648 | –6042 | –6033 | –6219 |

Ничәнче елда Брянск өлкәсендә үлүчеләр санының туучылар саныннан артыклыгы иң түбән булган?

**1)** 2011 ел

**2)** 2012 ел

**3)** 2013 ел

**4)** 2014 ел

991. 2014 нче елда Брянск өлкәсе халкының миграцион үсешен билгеләгез. Җавабыгызны саннарда чагылдырыгыз.

992. Воронеж өлкәсендә халык саны үзгәрү (кеше )

| | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел |
|---|---|---|---|---|
| Халык санының бер елда гомуми үсеше | –3303 | –1129 | –1418 | 2188 |
| Халык санының бер елда табигый үсеше | –13 166 | –11 081 | –11 275 | –6219 |

2014 нче елда Воронеж өлкәсе халкының миграцион үсешен билгеләгез. Җавабыгызны саннарда чагылдырыгыз.

993. Ничәнче елда Воронеж өлкәсендә үлүчеләр санының туучылар санынннан артыклыгы иң түбән булган?

1) 2011 ел

2) 2012 ел

**3)** 2013 ел

**4)** 2014 ел

994. Воронеж өлкәсендә халык саны үзгәрү (кеше)

| | 2011 ел | 2012 ел | 2013 ел | 2014 ел |
|---|---|---|---|---|
| Халык санының бер елда гомуми үсеше | –3303 | –1129 | –1418 | 2188 |
| Халык санының бер елда табигый үсеше | –13 166 | –11 081 | –11 275 | –6219 |

Ничәнче елда Воронеж өлкәсендә үлүчеләр санының туучылар саныннан артыклыгы иң югары булган?

**1)** 2011 ел

**2)** 2012 ел

**3)** 2013 ел

**4)** 2014 ел

995. 2013 нче елда Воронеж өлкәсе халкының миграцион үсешен билгеләгез. Җавабыгызны саннарда чагылдырыгыз.

996. 2012 нче елда Россиядә Рус утравында Азия-Тын океан икътисади хезмәттәшлеге оешмасына кергән дәүләт җитәкчеләренең (АТЭС) очрашуы була. Бу чараны үткәрү өчен Владивостокта берничә объект төзиләр, алар арасында Золотой Рог (Алтын мөгез) бухтасы аша Рус утравына кадәр төзелгән күпер дә була. Утрауның үзендә дүрт мини-ТЭЦ һәм бер җил электростанциясе дә төзелә. Җил электростанцияләре эшләсен өчен Рус утравына күзәтелә торган даими һәм шактый көчле җилләр булу кирәк.

АТЭС дәүләтләре башлыкларының очрашу урыны буларак урынны җентеклерәк өйрәнер өчен Россиянең кайсы географик районы картасын сайларга кирәк?

**1)** Магадан өлкәсе

**2)** Камчатка крае

**3)** Приморье крае

**4)** Чукотка автономияле округы

997. Электроэнергия җитештерүдә җил электростанцияләренең ТЭСта электроэнергиясе җитештерү белән чагыштырганда үз өстенлекләре бар. Шундый ике өстенлекне күрсәтегез.

Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремнең номерын языгыз.

---

998. Байкал арьягында 1789 нчы елда Петр I хөрмәтенә аталган Петровский Завод поселогы төзелә. Ул чуен кою һәм җирле тимер рудаларыннан тимер эшләү заводлары арасына төзелә. Посёлок аша Транссебер магистрале уздырылганнан соң, тимер юл станциясенә дә Петровский Завод атамасы бирелә. Соңрак посёлок шәһәр статусы ала, һәм аның атамасы Петровск-Забайкальск атамасына алмаштырыла. Шәһәр Байкал арьягы краендагы таулар арасындагы котлованда урнашкан. Һавасы пычрану ягыннан Россиядәге аеруча дәрәҗәдә пычранган шәһәрләре исәбендә йөргән. Кышын атмосфера һавасының пычрану дәрәҗәсе аеруча югары.

Түбәндә китерелгән шәһәрләрнең кайсы Петровск-Забайкальский кебек үк Транссебер тимер юл магистралендә урнашкан?

**1)** Чита

**2)** Якутск

**3)** Верхоянск

**4)** Охотск

999. Ни өчен, кагыйдә буларак, тау аралары котловиналарында урнашкан шәһәрләрдә, атмосфера һавасының югары дәрәҗәдә пычрануы күзәтелә? Ни өчен Себернең күп шәһәрләрендә атмосфера һавасының пычрану дәрәҗәсе аеруча кыш көне югары?

Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремнең номерын языгыз.

1000. Камчатка энергетикасының үзенчәлеге булып, барлык энергообъектларының үзенчәлекле табигать шартлы зонада эшләве тора. Шуның аркасында Камчатка Россиянең нинди дә булса берләштерелгән энергосистемасына, шул исәптән, Ерак Көнчыгыш энергосистемасына керми һәм объектив рәвештә керә дә алмый. Шул сәбәпләр аркасында югары көчәнешле ЛЭП тарафыннан эксплуатацияләнә дә алмый, бу бердәм территориаль энергосистема барлыкка китерүгә комачаулый.

Камчаткадагы табигать шартларына хас булган нинди үзенчәлекләр ЛЭП ны ышанычлы эксплуатацияләргә мөмкинлек бирмиләр, еш кына аларның зарарлануына китерәләр? Ике үзенчәлеген күрсәтегез. Җавабыгызны аерым биткә яки бланкка языгыз, башта биремнең номерын языгыз.